Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Кече Талкыш авыл җирлеге Советы

Карары

2026 елның 16 феврале №7/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Кече Талкыш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Кече Талкыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында»гы 10.02.2023 елның №30/1 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 28.11.2025 ел, №432-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Кече Талкыш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Кече Талкыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында «10.02.2023 ел, № 30/1 Чистай шәһәр Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Кече Талкыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5.1 маддәнең 7 пунктында «(муниципаль берәмлек)» сүзләреннән соң «, әгәр күрсәтелгән акчалар федераль казначылык органнары тарафыннан ачыкланмаган керемнәргә керсә һәм тиешле казначылык счетларында исәпкә алынса, бу очрактан тыш,» сүзләрен өстәргә.;

1.2. 5.1 маддәнең 13 пунктында «федераль законнар» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясе субъекты законнары, җирле үзидарә вәкиллекле органының муниципаль хокукый актлары» сүзләрен өстәргә.;

1.3. 5.1 маддәнең 11 пунктындагы 1 пунктчасының бишенче абзацында «контрактлар (шартнамәләр)» сүзләреннән соң «товарлар кайтару, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында» сүзләрен өстәргә.;

1.4. 5.1 маддәнең 11 пунктының 4 пунктчасында «коммерциягә карамаган оешмаларга» сүзләреннән соң «(шартларында казначылык озатуы турындагы нигезләмәләр булган дәүләт контрактлары, шартнамәләр (килешүләр), контрактлар (шартнамәләр) нигезендә бирелә торган акчалардан тыш)» сүзләрен өстәргә.;

1.5. 5 маддәнең 12 пунктындагы 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 221 маддәсе нигезендә билгеләнә торган тәртиптә бюджет сметасын төзи, раслый һәм алып бара.»

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга) һәм Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтына (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Авыл җирлеге башлыгы Г.Н.Федотов